РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ**
**ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ**
**ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 11 декабре** **Чистай шәһәре** **№42/7**

2019 елга һәм 2020-2021 елларның
планлы чорына Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
«Чистай шәһәре» муниципаль
берәмлеге бюджетына
үзгәрешләр кертү хакында

Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе Наталья Анфиногентовна Кармантованың “2019 елга һәм 2020-2021 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетына үзгәрешләр кертү хакында”гы докладын тыңлап һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2019 елга һәм 2020-2021 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы 2018 елның 25 декабрендәге 30/2 номерлы Чистай шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертергә, түбәндәге эчтәлекле 9 статьяны өстәргә:

«2019 елның җәйге чорында халыкның ташламалы категориясен бакчачылык җәмгыятьләренә ташламалы рәвештә ташуны оештыру турында»гы 2019 елның 30 нчы апрелендәге, 34/3 номерлы Чистай шәһәр Советы карары һәм Чистай шәһәре халкына автотранспорт маршрутлары хезмәте күрсәтү буенча 2018 елның 28 нче декабрендәге 33 номерлы шартнамәсе нигезендә, «Экспресс» ҖЧҖен бакчачылык ширкәтләренә халыкның ташламалы категориясен йөрткән өчен төшеп калган керемнәрне компенсацияләүгә 114 793,0 сум күләмендә субсидия бирергә.

«2019 елның җәйге чорында халыкның ташламалы категориясен бакчачылык җәмгыятьләренә ташламалы рәвештә ташуны оештыру турында»гы 2019 елның 30 нчы апрелендәге, 34/3 номерлы Чистай шәһәр Советы карары һәм

Чистай шәһәре халкына автотранспорт маршрутлары хезмәте күрсәтү буенча 2018 елның 28 нче декабрендәге 32 номерлы шартнамәсе нигезендә, «Экспресс+» ҖЧҖен бакчачылык ширкәтләренә халыкның ташламалы категориясен йөрткән өчен төшеп калган керемнәрне компенсацияләүгә 385 207,0 сум күләмендә субсидия бирергә.

2. Чистай шәһәр Советының 2019 елның 27 ноябрендәге 41/1 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында яисә «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет һәм фаразлау, сәнәгать һәм эшкуарлык буенча даими депутат комиссиясенә Н.В. Миңнегалиевка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов